МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.06.2018 г.Казань № 507

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 17 июлендә 4792 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының аерым боерыкларының көчен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Балалы гражданнарга дәүләт пособиеләре билгеләү буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләре өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламент раслау турында» 2018 елның 23 мартындагы 186н номерлы боерыгы чыгарылуга бәйле рәвештә б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының түбәндәге боерыкларын көчен югалткан дип танырга:

«Бала туганда бер бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 638 номерлы;

«Бала карау буенча айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 640 номерлы;

«Оешма бетерелүгә, физик затларның шәхси эшкуар сыйфатындагы эшчәнлекләрен туктатуына, хосусый тәҗрибә белән шөгыльләнүче нотариусларның үз вәкаләтләрен туктатуына һәм адвокат статусы туктатылуга бәйле рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлекләре федераль законнар нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга һәм (яисә) лицензияләнергә тиешле башка физик затларның үз эшчәнлекләрен туктатуына бәйле рәвештә, аларны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану көненнән алда килгән унике ай эчендә эштән азат ителгән хатын-кызларга йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие билгеләү буенча дәүләт

хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 642 номерлы;

«Оешма бетерелүгә, физик затларның шәхси эшкуар сыйфатындагы эшчәнлекләрен туктатуына, хосусый тәҗрибә белән шөгыльләнүче нотариусларның үз вәкаләтләрен туктатуына һәм адвокат статусы туктатылуга бәйле рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлекләре федераль законнар нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга һәм (яисә) лицензияләнергә тиешле башка физик затларның үз эшчәнлекләрен туктатуына бәйле рәвештә, аларны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану көненнән алда килгән унике ай эчендә эштән азат ителгән, йөклелегенең иртәнге чорында (унике атна узганчыга кадәр) медицина оешмаларында исәпкә алынган хатын-кызларга бер бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 02 февралендәге 64 номерлы;

«Чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәр баласына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 10 апрелендәге 224 номерлы;

«Чакырылыш буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 10 апрелендәге 225 номерлы;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Оешма бетерелүгә, физик затларның шәхси эшкуар сыйфатындагы эшчәнлекләрен туктатуына, хосусый тәҗрибә белән шөгыльләнүче нотариусларның үз вәкаләтләрен туктатуына һәм адвокат статусы туктатылуга бәйле рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлекләре федераль законнар нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга һәм (яисә) лицензияләнергә тиешле башка физик затларның үз эшчәнлекләрен туктатуына бәйле рәвештә, аларны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану көненнән алда килгән унике ай эчендә эштән азат ителгән, йөклелегенең иртәнге чорында (унике атна узганчыга кадәр) медицина оешмаларында исәпкә алынган хатын-кызларга бер бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 02 февралендәге 64 номерлы боерыгы белән расланган Оешма бетерелүгә, физик затларның шәхси эшкуар сыйфатындагы эшчәнлекләрен туктатуына, хосусый тәҗрибә белән шөгыльләнүче нотариусларның үз вәкаләтләрен туктатуына һәм адвокат статусы туктатылуга бәйле рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлекләре федераль законнар нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга һәм (яисә) лицензияләнергә тиешле башка физик затларның үз эшчәнлекләрен туктатуына бәйле рәвештә, аларны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану көненнән алда килгән унике ай эчендә эштән азат ителгән, йөклелегенең иртәнге чорында (унике атна узганчыга кадәр) медицина оешмаларында исәпкә алынган хатын-кызларга бер бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 12 октябрендәге 728 номерлы;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Оешма бетерелүгә, физик затларның шәхси эшкуар

сыйфатындагы эшчәнлекләрен туктатуына, хосусый тәҗрибә белән шөгыльләнүче нотариусларның үз вәкаләтләрен туктатуына һәм адвокат статусы туктатылуга бәйле рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлекләре федераль законнар нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга һәм (яисә) лицензияләнергә тиешле башка физик затларның үз эшчәнлекләрен туктатуына бәйле рәвештә, аларны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану көненнән алда килгән унике ай эчендә эштән азат ителгән хатын-кызларга йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 642 номерлы боерыгы белән расланган Оешма бетерелүгә, физик затларның шәхси эшкуар сыйфатындагы эшчәнлекләрен туктатуына, хосусый тәҗрибә белән шөгыльләнүче нотариусларның үз вәкаләтләрен туктатуына һәм адвокат статусы туктатылуга бәйле рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлекләре федераль законнар нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга һәм (яисә) лицензияләнергә тиеш булган башка физик затларның үз эшчәнлекләрен туктатуына бәйле рәвештә, аларны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану көненнән алда килгән унике ай эчендә эштән азат ителгән хатын-кызларга йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 12 октябрендәге 729 номерлы;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Бала туганда бер бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 638 номерлы боерыгы белән расланган Бала туганда бер бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 12 октябрендәге 731 номерлы;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Бала карау буенча айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 640 номерлы боерыгы белән расланган Бала карау буенча айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 12 октябрендәге 732 номерлы;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 07 июнендәге 317 номерлы боерыгы белән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелгән үзгәрешләрнең 35-38, 47-48 пунктлары;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 26 июнендәге 416 номерлы боерыгы белән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелгән үзгәрешләрнең 2 пункты;

«Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 24 июлендәге 504 номерлы;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 07 маендагы 349 номерлы боерыгы белән халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелгән үзгәрешләрнең 4 пункты;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 07 маендагы 350 номерлы боерыгы белән халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелгән үзгәрешләрнең 1-2, 7 пунктлары;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 07 маендагы 352 номерлы боерыгы белән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелгән үзгәрешләрнең 1 пункты.

Министр Э.Ә. Зарипова